**ГЛАВА ШАПШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422708, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Шапши, ул.Ленина, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘПШИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Шәпши авылы, Ленин ур, 1

Тел./факс: +7(84365) 77-2-36, e-mail: Shap.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» ноябрь 2021 ел № 3

**Шәпше авылында халык җыенын билгеләү турында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча киңәшмә**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге Уставының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22 маддәсе һәм 23.10.2009 ел, №163 карары (08.05.2020 ел, 09.10.2020 ел, №6 редакциясендә) нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге башлыгы

**КАРАРЫ:**

1. 2021 елның 18 ноябрендә 18.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. 2021 елның 19 ноябрендә 18.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
3. 2021 елның 20 ноябрендә 18.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1.Шәпше авылы зиратын киртәләп алу, смета һәм килешү буенча түләү;

2.Шәпше авылында янгын гидрантларын урнаштыру өчен гидрантлар сатып алу, смета һәм килешү буенча эшләр өчен түләү;

3.МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу

**«ӘЙЕ»** **«КАРШЫ»**

5.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы ____________ В.А.Беляков